ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ КАЙБИЦКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ КАЙБЫЧ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

15.07.2024 Олы Кайбыч ав. № 248

Кайбыч муниципаль районы Башкарма комитетының 2016 елның 30 декабрендәге 543 номерлы карары белән расланган Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районы Башкарма комитетында гражданнар мөрәҗәгатьләрен карау тәртибенә үзгәрешләр кертү турында

«Татарстан Республикасында гражданнарның мөрәҗәгатьләре турында» Татарстан Республикасы Законына үзгәрешләр кертү хакында» 2023 елның 09 декабрендәге 124-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы нигезендә, Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районының Башкарма комитеты КАРАР ИТӘ:

1. Кайбыч муниципаль районы Башкарма комитетының 2016 елның 30 декабрендәге 543 номерлы карары белән расланган Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районы Башкарма комитетында гражданнар мөрәҗәгатьләрен карау тәртибенә түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

- 1.2. пунктының 3 абзацында «электрон почта адресы» сүзләреннән соң «яисә Бердәм порталдагы шәхси кабинет адресы» сүзләрен өстәргә;
- 2.15 пунктының 2 абзацын «яисә Бердәм порталдагы шәхси кабинет адресы» сүзләре белән тулыландырырга.

2. Әлеге карарны Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә http:/kaybici.tatarstan.ru веб-адресы буенча Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районының рәсми сайтында урнаштырырга һәм http://pravo.tatarstan.ru веб-адресы буенча «Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат рәсми порталында» бастырып чыгарырга.

3. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районы Башкарма комитеты эшләре идарәчесе Д.А. Бәдертдиновага йөкләргә.

Җитәкче А.Н.Макаров